| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЗЕЛЕНАЯ РОЩА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

2023 елның 26 октябре №71

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 5 декабрендәге 24 номерлы карары белән расланган «2023-2024 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» җирләрен файдалану һәм саклау» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 21 июлендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 5 декабрендәге 24 номерлы карары белән расланган «2023-2024 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» җирләрен файдалану һәм саклау» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 бүлекнең 2 абзацында «авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфракның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту өчен» сүзләрен «җирләрнең үзлекләрен яхшырту, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу өчен» сүзләренә алмаштырырга (2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зеленая Роща авылы, Тәзелеш урамы, 1 йорт, Мингәрәев исемендәге АКЦ, Спиридоновка авылы, Совет урамы, 32нче йорт Спиридоновка мәдәният йорты бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында,Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымлда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Зеленая Роща авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А.Потапов.